КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 июнь г.Казань № 740

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында куллану калдыклары белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү чаралары турында» 2006 ел, 05 июль, 344 нче;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында хәвефле каты коммуналь калдыклар җыю өчен зур сыйдырышлы махсуслаштырылган контейнерлар сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 9 октябрь, 770 нче;

«2020 елда каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча юридик затларга - «Экология» илкүләм проектының «Каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасы» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче төбәк операторларына каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча өзлексез эшне тәэмин итүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 25 декабрь, 1184 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин